Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Советының утыз икенче утырышы

КАРАР

4 июнь, 2018 ел № 104

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советы карары хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставының 86, 87, 88 статьялары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советының беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советы карары проекты буенча «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гавами тыңлаулар уздыру тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. 2018 елның 29 июненә «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

Ачык тыңлаулар үткәрү урыны итеп Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Чыты авылы, Кооператив урамы, 85 й., 14.00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты фойесын билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советының түбәндәге составта карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеме төзергә:

- Фәйзрахманов Самат Әхәтович – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге башлыгы, эш төркеме рәисе;

- Гайнутдинова Айгөл Дамировна – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге Советы депутаты, эш төркеме әгъзасы;

- Шәйхетдинов Дамир Сәйфетдинович – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге Советы депутаты, эшче төркем әгъзасы.

5. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советының халык алдында тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып һәм аның турында фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрен исәпкә алып, һәм икенче укылышта кабул итү өчен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге советын карауга карар проектын кертергә.

6. «Вперед» район газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов